| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 14.04.2017 г. Казань № 3-2/э

Татарстан Республикасының «Электр челтәрләре» дәүләт унитар предприятиесе һәм «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыятьләре тарафыннан электр энергиясен тапшыру хезмәтләре өчен челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау буенча аерым тарифлар билгеләү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (кулланучылар) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифларны һәм бәяләрне хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә кирәкле тулай табышны дәвамлы индексацияләү ысулын кулланып билгеләнә торган тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Карар үз көченә кергән көннән башлап 2017 елның 31 декабренә кадәр, шушы карарның 1 кушымтасына туры китереп, Татарстан Республикасының «Электр челтәрләре» дәүләт унитар предприятиесе һәм «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыятьләре тарафыннан электр энергиясен тапшыру хезмәтләре өчен челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау буенча календарь буенча бүленгән аерым тарифлар билгеләргә.

2. Карар үз көченә кергән көннән башлап 2017 елның 31 декабренә кадәр, шушы карарның 2 кушымтасына туры китереп, «Электр челтәрләре» дәүләт унитар предприятиесенең зарури тулай табышын (югалтулар өчен түләүләрне исәпкә алмыйча) билгеләргә.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
14.04.2017 ел № 3-2/т карарына
1 кушымта

Карар үз көченә кергән көннән башлап 2017 елның 31 декабренә кадәр
Татарстан Республикасының «Электр челтәрләре» дәүләт унитар предприятиесе һәм «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыятьләре тарафыннан электр энергиясен тапшыру хезмәтләре өчен челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау буенча календарь буенча бүленгән
аерым тарифлар

| № п/п | Челтәр оешмасының аталышы | Ел | карар үз көченә кергән көннән башлап 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт.ай | сум/МВт.сәг | сум/кВт.сәг | сум/МВт.ай | сум/МВт.сәг | сум/кВт.сәг |
| 1 | Татарстан Республикасының «Электр челтәрләре» дәүләт унитар предприятиесе – «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте | 2017 | 134 878,90 | 62,69 | 0,40342 | 134 878,90 | 74,42 | 0,41514 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
14.04.2017 ел № 3-2/т карарына
2 кушымта

Карар үз көченә кергән көннән башлап 2017 елның 31 декабренә кадәр
«Электр челтәрләре» дәүләт унитар предприятиесенең зарури тулай табышы
(югалтулар өчен түләүләрне исәпкә алмыйча)

| № п/п | Татарстан Республикасында челтәр оешмасының аталышы | Ел | Югалтулар өчен түләүне исәпкә алмыйча, челтәр оешмасының ЗТТ |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1 | Татарстан Республикасының «Электр челтәрләре» дәүләт унитар предприятиесе | карар үз көченә кергән көннән башлап 2017 елның 31 декабренә кадәр | 193740,05 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге